

Изге Корбан бәйрәме яки Корбан гаете - Ураза бәйрәме тәмамлангач 70 кон узуга, Золхижжә аенын унынчы конендә, быел алтынчы июньгә туры килде, билгеләнә. Моселманнарнын ин зур бәйрәме булып санала. Мордовия авыллары һәм шәһәрләре мәчетләрендә, шул исәптән Темников шәһәре мәчетендә беренче тапкыр, Бәйрәмгә каршы тондә вәгазьләр сойләнде, иртән Гает намазы укылды.
Мордовиядәге моселманнарыбыз һәр бәйрәм алдыннан, башка чакта да, зиратта яткан кардәшләренен каберлекләрен жыештырып торалар, догасын укыйлар һәм гает коннәрендә туганнары яткан изге урынга барып кайталар.  Корбан гаете – корбан чалып Аллаһынын рәхмәтенә ирешv бәйрәме. Ә корбан чалу – ул фида кылу, жанын-тәнен белән Яралтучыга бирелv, буйсыну, Ана ихластан рәхмәтле булу, Анын ризалыгына игелекләр һәм мохтажларга ярдәм аша омтылу. Әлеге бәйрәмне кемнен кvнеленә ничек хуш килә, шулай vткәрделәр, тик дини елаларга таянып.
Мохтәрәм милләттәшләр! Кардәшләребезнен ин бәхетлеләре хажда булса, икенче бер олеше махсус хәрби операциядә хезмәт итә. Мохтәрәм моселман хәрбиләре, Ватаныбызны саклаучылар! Сезгә vзебезнен ихлас сәламнәребезне жибәрәбез һәм бәйрәм белән котлыйбыз.
Шушы мокатдәс гает коннәрендә барлык моселманнарга да чалган корбаннарнын, укыган догаларнын һәм кылган игелекләрнен Аллаһы Тәгалә тарафыннан кабул ителсен. Ойләребездә бәрәкәт, иминлек булып, иман нуры балкып торсын!